КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 июль г.Казань № 879

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы бюджет учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы бюджет учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1041 нче; 2019 ел, 26 ноябрь, 1080 нче; 2020 ел, 3 февраль, 69 нчы; 2020 ел, 14 апрель, 281 нче; 2020 ел, 23 июнь, 521 нче; 2020 ел,

4 ноябрь, 991 нче; 2021 ел, 25 февраль, 98 нче; 2021 ел, 20 октябрь, 989 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә, 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «з$^{1}$» пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«з$^{1}$) бюджетлар керемнәре администраторлары тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм аларның штрафлары буенча дебитор бурычын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгеләү турында таләп;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин